Республикабызда хәзерге чорда да балалар хәрәкәте көчәйгәннән-көчәя бара. Мәктәбебезнең пионер оешмасы күп еллар буе Юрий Алексеевич Гагарин исемен йөрткән. Татарстан варис - пионерлар берлеге оешканнан соң, бу оешманың методлары буенча, мәктәбебез варис пионерлар оешмасы - "КОЯШ" дип атала башлаган. Ул Кыю Омтылыш Яшәү Шартыбыз дип таркатыла.

Девизыбыз: Һәркөнне игелекле эш эшлә!

Балалар хәрәкәтенең эшчәнлеген үз вакытында беренче президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев та хуплап: "Без республикабызның киләчәген сезнең белән, сезнең хезмәт итә, дус була белүегез, традицияләрне саклый, ихтирам итә һәм үстерә белүегез белән бәйләп карыйбыз.

Балалар хәрәкәте тарихы безнең халыкның тарихыннан аерылгысыз һәм ул балалар оешмаларының югарыдан көчләп тагылган түгел, ә яшьләргә органик рәвештә хас булган оешма булуы турындагы фикерне бик ачык раслый",- дип белдергән иде ул Татарстан варислары берлегенә котлавында.

Без, әлбәттә, үзебезнең Татарстан варислары берлеге әгъзасы булуыбыз белән чиксез горурланабыз. Киләчәктә дә балалар оешмаларының янып, гөрләп яшәвен телибез.

"Балалар оешмасы элек һәм бүген"

- Күңеллерәк булган, оешканрак, әле бит быргы белән барабан үзе генә ни торган.
- Миңа хәзер дә күңелсез түгел. Безнең "КОЯШ" оешмасында күңелсезләнеп утырырга вакыт бармы?
    - Темага якынрак килик. Кем ул пионер?
    - Советлар Союзы Коммунистлар партиясе эше өчен һәрвакыт әзер булган кеше!
    - Үз заманының чын герое.
    - Кем ул варис?
    - Һәрвакыт игелек кылырга әзер бул!
    - Һәрвакыт әзер!
    - Аерма күренми.
    - Отряд, дружина сборлары...
    - Чиреккә бер дружина сборы, оешма утырышлары.
    - План, карар, эшкә анализ – аерма зур түгел.
    - Бөтенсоюз слетлары.
    - Әйе, слетлар күренми, әмма балалар Думасы бу эшнең уңышлы башлангычы булыр дип уйлыйм.
    - Тимур һәм аның командасы!
    - Валантерлар, Хәйрия елы, ярдәмгә мохтаж олыларга булышу – безнең дә төп эшебезнең берсе.
    - Макулатура, металлолом, икенче чимал җыю.
    - "Җиребезне чүп-чардан чистартыйк!" акциясе!
    - Карагыз әле, бер уйлаганда, аерма бик зур түгел!

- **"КОЯШ" нәрсә аңлата?**
- Яшәү рәвеше.
- Сәламәт яшәү рәвешен сайлаган кебек, без "КОЯШ" оешмасын сайлыйбыз!

- **"КОЯШ" безгә нәрсә бирә?**
- Файдалы, күңелле, онытылмаслык яшәү рәвеше!
- Мөстәкыйльлек.
- Фикер киңлеге.
- Иҗадилык.
- Елмаю,

- яхшы кәеф,
- яңа дуслар...

- **“КОЯШ” безне нәрсәгә өйрәтә?**
- Сау-сәламәт
- Зыялы
- Кешелекле
- Рухи зәвыклы
- Югары әхлаклы
- Туган ягыбызның табигатен
- Халкыбызның тарихи мирасын саклаучы
- Туган республикабызның, илебезнең лаеклы гражданины булырга!

**“КОЯШ” - ул безнең дөнья!**
**Таң булып атарбыз,**
**Кояш булып балкырбыз!**